СОВЕТ ВЕРХНЕОШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с..Верхняя Ошма, д.54 а, с. Верхняя Ошма,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422163

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ УШМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет ур., №54а нче йорт,ЮгарыУшма авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422163

тел.(факс): (85563) 2-32-36; e-mail: Voshm.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ
№ 3-22

КАРАР
от «20» февраль 2023 ел

ТР Мамадыш муниципаль районы
Югары Ушма авыл җирлеге
Советының аерым карарларының
үз көчләрен югалтуын тану
турында

Муниципаль хокукый актлар системасын актуальләштерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Советы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Түбәндәге карарларны үз көчен югалтты дип танырга:
- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Советының 2005 елның 12 ноябрендәге «Җир налогы турында» 4-2 номерлы карары;

- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Советының 2006 елның 1 августындагы «Югары Ушма авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс турында» 6-11 номерлы карары.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районының Югары Ушма авыл җирлеге башлыгы И.З.Исмагиловка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы

Югары Ушма авыл җирлеге

Советы рәисе, җирлек башлыгы /И.З.Исмагилов/